Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Кибәк Иле авыл җирлеге Советы

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Кибәк Иле авыл җирлеге Башлыгы
КАРАРЫ

2 октябрь, 2024 ел № 2

Питрәч муниципаль районы Кибәк Иле авыл җирлеге Кибәк Иле авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җыен билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Питрәч муниципаль районы Кибәк Иле авыл җирлеге уставының 22 статьясы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Кибәк Иле авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә нигезендә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының 2019 елның 08 ноябрендәге 139 номерлы Кибәк Иле авыл җирлеге Советы карары (2021 елның 13 декабрендәге 34 номерлы карары белән расланган үзгәрешләр белән) нигезендә карар бирәм:

1. Кибәк Иле авылы җирлегендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

Гражданнар җыенын ике этапта уздырырга:

- гражданнар җыенының беренче этабы 2024 елның 15 октябрендә 10 сәгать 00 минутта Тукай урамы, 28 й. адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында. Җыенда катнашучылар исемлегенә Яшел, Нариман, Яңа, Бакча урамнары буенча теркәлгән халыкны кертергә;

- гражданнар җыенының беренче этабы 2024 елның 15 октябрендә 13 сәгать 00 минутта Тукай урамы, 28 й. адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында. Җыенда катнашучылар исемлегенә Чишмә, Тукай, Мәктәп урамнары буенча теркәлгән халыкны кертергә;

«Сез, 2025 елда Кибәк Иле торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә, 1 төркем, эшләмәүче 2 төркем инвалидларны, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы студентлары, 80 яшькә җиткән гражданнар, махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен куллану белән килешәсезме?:

- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын төзекләндерү (чишмәләр) «РИЗА» «КАРШЫ».

2. Әлеге карарны «Вперед» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Кибәк Иле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

Питрәч муниципаль районы
Кибәк Иле авыл җирлеге башлыгы Р.Ә. Сәйфетдинов